**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2017-2018 уку елы). 10 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

**I. Теоретик биремнәр (35 балл).**

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең авторын, төрен һәм жанрын билгеләгез (20 балл):

*“Өч хатын белән тормыш”* – ***Г.Исхакый, драма төре, драма***

*“Урталыкта”* – ***Ф.Әмирхан, проза яки эпик төр, роман***

*“Хәят”* - ***Ф.Әмирхан, проза яки эпик төр, повесть***

*“Милли моңнар”* – ***Г.Тукай, поэзия яки лирик төр, күңел лирикасы яки шигырь***

*“Нуры содур”* – ***Мөхәммәдъяр, поэзия яки лиро-эпик төр, поэма***

2. М.Җәлилнең “Җырларым” шигыреннән алынган әлеге өзекнең нинди үлчәмдә язылганлыгын һәм ничек рифмалашуын (а, б, в шартлы билгеләре ярдәмендә) билгеләгез (5 балл):

*Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,*
*Ил кырында чәчәк атыгыз!*
*Күпме булса сездә көч һәм ялкын,*
*Шулкадәрле җирдә хакыгыз!..* ***10 / 9, а-б-в-б***

3. Әлеге билгеләмәләрдән романтизм төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (5 балл):

*1)* ***билгеле бер идеал яктылыгында тормышны үзгәртеп, арттырып тасвирлауга нигезләнгән иҗат юнәлеше;***

*2) билгеле бер тормыштан алынган вакыйга яктылыгында тормышны булганынча тасвирлауга нигезләнгән иҗат юнәлеше;*

*3) билгеле бер геройга бәйле вакыйга яктылыгында шул геройның тормыш юлын тасвирлау;*

*4) билгеле бер геройның тормышындагы бер чорны сурәтләү.*

4. Мәгърифәтчелек реализмына мөнәсәбәтле әсәрләрдә урын ала (5 балл):

*А)* ***укучыны югары идеалларга, рухи камиллеккә, аң-белемгә өндәү;***

*Б) укучыны югары мәхәббәт идеалларына, рухи камиллеккә өндәү;*

*В) укучыны югары идеалларга, дини булырга өндәү;*

*Г) укучыны әти-әнигә карата мәрхәмәтле булырга өндәү.*

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).**

1. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повестенда Гариф язмышы ничек тәмамлана? (5 балл) ***Газизә белән хушлашып, юллык акча туплау нияте белән эш эзләп китә...***

2. *“Мин сине көтәрмен” дигән җөмлә аның колак янында әллә нинди югары һәм эч өзгеч ноталардан җырланып бара, аның җанын ләззәт белән сагыш катыш ачыта, сызлата иде*” өзегендә кем кичерешләре турында сүз бара? Ни өчен әлеге герой күңелендә шундый сызлану барлыкка килә? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез. (10 балл)

**Гариф. Ул Газизә белән аерыла, сөйгәненнән аерылып, акча эшләргә китәргә мәҗбүр була, шуңа күңеле сызлана.**

3. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повесте мисалында әсәр исеменең сюжет белән бәйләнешен билгеләп карагыз, язучы ни өчен нәкъ шушы исемне сайлаган дип уйлыйсыз? (15 балл) ***Акчарлаклар дигәндә сезонлы эшчеләр күздә тотыла. Шартлы образ буларак, эшчеләрнең күңел кичерешләре, омтылышлары, хыяллары, аларның чынга ашмавы акчарлаклар образы ярдәмендә җиткерелә...***

4. “*Гариф барганда Газизә күлмәкчән генә* ***кара шәл*** *бөркәнеп ишек алды баскычында утырып тора иде. Ерактан ук Гарифның күзенә күңелсезләнеп, кайгырып утыра төсле күренде*” дигән өзектә кара шәл образы нинди күчерелмә мәгънәдә кулланыла? Әсәр сюжетына бәйләп аңлатыгыз. (15 балл) ***Кара шәл образы Газизә күңелендәге Гариф белән аерылышуга бәйле туган сагыш, кайгыны, авыр тормышны чагылдырып килә...***

**III. Иҗади бирем (20 балл).**

1. *Ара бик якын да, ара бик ерак та иде...* Текстны дәвам итеп, кечкенә генә хикәя языгыз.